МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.11.2016 № 668

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 21 декабрендә теркәлде, № 3760

**Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең**
**аерым административ регламентларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту буенча федераль хезмәте һәм Миграция федераль хезмәте бетерелүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президентының “Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнешен контрольдә тоту өлкәсендә һәм миграция өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү турында” 2016 елның 5 апрелендәге № 156 Указына туры китереп **боерык бирәм**:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымта итеп бирелүче үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 28.11.2016 ел, № 668 боерыгы белән расландылар

**Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 19.11.2014 ел, № 634 боерыгы белән расланган административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 ел, № 461; 09.11.2015 ел, № 821; 07.06.2016 ел, № 317; 20.07.2016 ел, № 420 боерыклары керткән үзгәрешләр белән):

2 нче бүлектәге 2.6 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында “Миграция федераль хезмәтендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында” сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче бүлекнең 3.4.2 пунктында:

ундүртенче абзацта “Миграция федераль хезмәтендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында” сүзләре белән алмаштырырга;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган һәм “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның “Социаль ярдәм күрсәтү чаралары” кече системасына кертелгән мәгълүматлар, мәгълүматлар тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр.”.

2. Балага ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Балага ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 19.11.2014 ел, № 643 боерыгы белән расланган административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 ел, № 533; 06.06.2016 ел, № 316 боерыклары керткән үзгәрешләр белән):

2 нче бүлектәге 2.6 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында “Миграция федераль хезмәтендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында” сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче бүлекнең 3.4.2 пунктында:

унынчы абзацта “Миграция федераль хезмәтенә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына” сүзләре белән алмаштырырга;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган һәм “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның “Социаль ярдәм күрсәтү чаралары” кече системасына кертелгән мәгълүматлар, мәгълүматлар тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр.”.

3. Ата-аналарның мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балага күз-колак булган һәм карап-тәрбияләп торган өчен түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Ата-аналарның

мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балага күз-колак булган һәм карап-тәрбияләп торган өчен түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” 19.11.2014 ел, № 639 боерыгы белән расланган административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 12.10.2015 ел, № 730; 19.05.2016 ел, № 278 боерыклары керткән үзгәрешләр белән):

2 нче бүлектәге 2.6 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында “Миграция федераль хезмәтендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында” сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче бүлекнең 3.4 пунктындагы 3.4.2 пунктчасында:

сигезенче абзацта “Миграция федераль хезмәтенә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына” сүзләре белән алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган һәм “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның “Социаль ярдәм күрсәтү чаралары” кече системасына кертелгән мәгълүматлар, мәгълүматлар тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр.”.

4. 18 яшькә кадәрле яшьтәге өч һәм аннан артык балалы (тәрбиягә алынганнарын да кертеп) гаиләләрдән булган 6 яшькә кадәрле яшьтәге бала өчен дарулар сатып алуга субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “18 яшькә кадәрле яшьтәге өч һәм аннан артык балалы (тәрбиягә алынганнарын да кертеп) гаиләләрдән булган 6 яшькә кадәрле яшьтәге бала өчен дарулар сатып алуга субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 08.12.2014 ел, № 674 боерыгы белән расланган административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин

итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2016 ел, № 314 боерыгы керткән үзгәрешләр белән):

2 нче бүлектәге 2.6 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында “Миграция федераль хезмәтендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында” сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче бүлекнең 3.4 пунктындагы 3.4.2 пунктчасында:

алтынчы абзацта “Миграция федераль хезмәтенә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына” сүзләре белән алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган һәм “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның “Социаль ярдәм күрсәтү чаралары” кече системасына кертелгән мәгълүматлар, мәгълүматлар тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр.”.

5. 18 яшькә кадәрле яшьтәге өч һәм аннан артык балалы (тәрбиягә алынганнарын да кертеп) гаиләләрдән булып, гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга, укуларын тәмамлаганчы, ләкин алар 18 яшькә җиткәнгә кадәр генә, юлда йөрүгә ай саен бирелә торган субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “18 яшькә кадәрле яшьтәге өч һәм аннан артык балалы (тәрбиягә алынганнарын да кертеп) гаиләләрдән булып, гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга, укуларын тәмамлаганчы, ләкин алар 18 яшькә җиткәнгә кадәр генә, юлда йөрүгә ай саен бирелә торган субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 08.12.2014 ел, № 675 боерыгы белән расланган административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2016 ел, № 315 боерыгы керткән үзгәрешләр белән):

2 нче бүлектәге 2.6 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында “Миграция федераль хезмәтендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында” сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче бүлекнең 3.4 пунктындагы 3.4.2 пунктчасында:

алтынчы абзацта “Миграция федераль хезмәтенә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына” сүзләре белән алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган һәм “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның “Социаль ярдәм күрсәтү чаралары” кече системасына кертелгән мәгълүматлар, мәгълүматлар тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр.”.

6. Пенсияләре “Иминият пенсияләре турында”, “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында” һәм “Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында” Федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юлда йөрүгә ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Пенсияләре “Иминият пенсияләре турында”, “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында” һәм “Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында” Федераль законнар нигезендә билгеләнеп, Татарстан Республикасында яшәүче, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган пенсионерларга юлда йөрүгә ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 17.11.2014 ел, № 628 боерыгы белән расланган административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин

итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 ел, № 317; 11.07.2016 ел, № 395 боерыклары керткән үзгәрешләр белән):

2 нче бүлектәге 2.6 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында “Миграция федераль хезмәтендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында” сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче бүлекнең 3.4.2 пунктында:

унынчы һәм унберенче абзацларда “Миграция федераль хезмәтенә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына” сүзләре белән алмаштырырга;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бу Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктлары билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кабул ителгән һәм теркәлгән көнне үтәлә.”;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган һәм “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның “Социаль ярдәм күрсәтү чаралары” кече системасына кертелгән мәгълүматлар, мәгълүматлар тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр.”.

7. 18 яшькә кадәрле яшьтәге өч һәм аннан артык балалы (тәрбиягә алынганнарын да кертеп) гаиләләргә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “18 яшькә кадәрле яшьтәге өч һәм аннан артык балалы (тәрбиягә алынганнарын да кертеп) гаиләләргә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” 01.12.2014 ел, № 670 боерыгы белән расланган административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.05.2016 ел, № 277 боерыгы керткән үзгәрешләр белән):

2 нче бүлектәге 2.6 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында “Миграция федераль хезмәтендә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында” сүзләре белән алмаштырырга;

3 нче бүлекнең 3.4 пунктында:

3.4.1 пунктның өченче абзацын сүзләр белән тулыландырырга:

“, идарәче компанияләрдән, җирле үзидарә органнарыннан”;

3.4.2 пунктчасында:

җиденче абзацта “Миграция федераль хезмәтенә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына” сүзләре белән алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бу Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктлары билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кабул ителгән һәм теркәлгән көнне үтәлә.”;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган һәм “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның “Социаль ярдәм күрсәтү чаралары” кече системасына кертелгән мәгълүматлар, мәгълүматлар тапшыру турында рәсми мөрәҗәгатьләр.”.